**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 26 » гыйнвар 2016 ел** **№ 26**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.04.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыру инициативасы турында» Арча шәһәр Советының 22.01.2016 ел, №24 карарына нигезләнеп, Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Арча шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алар өчен түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан һәм анда

катнашучылардан тыш, һәм акчаны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме, планлаштырылган чаралар, гамәлгә ашыру өчен акча күләме /сум

1. Төзекләндерүне оештыру, Казансу елгасы бассейны яр буендагы яшел үсентеләрне санитар кисү(160 метр)

Арча шәһәре Казансу елгасы бассейнының яр буе полосасының парк зонасын төзү (160 метр)

Торак пунктларда яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру:

- Арча шәһәре;
- Иске Айван авылы;
- Төбәк Чокырча авылы;
- Күпербаш авылы;
- Зур Бирәзә;
- В. Божа;

Барлыгы 5068000 сум.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, акчаны Арча шәһәре Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Башкарма комитетның административ бинасы (Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт); район мәдәният йорты (Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 йорт); КФҮ (Арча шәһәре, Һ. Такташ урамы, 58 йорт); Плодосовхоз авыл клубы (Арча шәһәре, Кленовая ур., 4 үзәк китапханәдә (Арча шәһәре, Банк ур., 2а) урнаштырырга.

4.Әлеге карар бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев